**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об учреждении грантов Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии

В целях совершенствования системы государственной поддержки организаций культуры, искусства и кинематографии, в соответствии с пунктом 4 статьи $78^1$ Бюджетного кодекса Российской Федерации, статьей $28^2$ Закона Республики Татарстан от 3 июля 1998 года № 1705 «О культуре» **постановляю:**

1. Учредить с 2021 года гранты Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии (далее также – гранты).

2. Утвердить прилагаемый перечень получателей грантов Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии (далее – получатели грантов).

3. Установить, что:

гранты выплачиваются получателям грантов ежегодно начиная с 2021 года;

общий размер бюджетных ассигнований бюджета Республики Татарстан на выплату грантов составляет 349 358,4 тыс. рублей в год.

4. Кабинету Министров Республики Татарстан:

утвердить порядок предоставления грантов;

определить размер гранта, выплачиваемого каждому получателю гранта, исходя из того, что он не может быть ниже размера гранта Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии, предоставленного соответствующему получателю гранта в 2019 году;

обеспечить финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа, за счет средств бюджета Республики Татарстан;

обеспечить осуществление контроля за целевым использованием грантов;

ежегодно при формировании бюджета Республики Татарстан предусматривать средства на выплату грантов;

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

5. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 2 апреля 2007 года № УП-168 «Об учреждении грантов Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии»;

Указ Президента Республики Татарстан от 23 марта 2015 года № УП-302 «О внесении изменения в Указ Президента Республики Татарстан «Об учреждении грантов Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии».

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
27 января 2021 года
№ УП-60

Утвержден
Указом Президента
Республики Татарстан

от «27» января 2021 года

№ УП-60

**Перечень**
**получателей грантов Президента Республики Татарстан**
**в области культуры, искусства и кинематографии**

1. Государственное бюджетное учреждение культуры «Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан».
2. Государственное автономное учреждение культуры Республики Татарстан «Государственный симфонический оркестр Республики Татарстан».
3. Государственное бюджетное учреждение культуры Республики Татарстан «Государственный фольклорный ансамбль кряшен «Бермянчек».
4. Государственное бюджетное учреждение культуры Республики Татарстан «Казанский академический русский Большой драматический театр имени В.И. Качалова».
5. Государственное бюджетное учреждение культуры Республики Татарстан «Татаркино».
6. Государственное бюджетное учреждение «Татарский академический государственный театр оперы и балета имени Мусы Джалиля».
7. Государственное бюджетное учреждение культуры Республики Татарстан «Татарская государственная филармония имени Габдуллы Тукая».
8. Государственное бюджетное учреждение «Татарский государственный Академический театр имени Галиасгара Камала».
9. Государственное бюджетное учреждение «Татарский государственный театр драмы и комедии им. К.Тинчурина».

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын гамәлгә кую турында**

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү системасын камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 4 пункты, «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының $28^2$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. 2021 елдан Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын (алга таба шулай ук – грантлар) гамәлгә куярга.

2. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын алучыларның (алга таба – грантлар алучылар) теркәлгән исемлеген расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:
грант алучыларга грантлар 2021 елдан алып ел саен түләнә;
Татарстан Республикасы бюджетының грантлар түләүгә бирелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме елына 349 358,4 мең сум тәшкил итә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
грантлар бирү тәртибен расларга;
грант алучының һәркайсына түләнә торган грант күләмен, аның 2019 елда әлеге грант алучыга бирелгән Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты гранты күләменнән азрак була алмавын күздә тотып, билгеләргә;
әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан финанслауны тәэмин итәргә;
грантларның тиешле максатларга сарыф ителүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә;
Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен грантлар түләүгә акча бүлүне күздә тотарга;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

5. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын гамәлгә кую турында» 2007 елның 2 апрелендәге ПУ-168 номерлы Указын;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын гамәлгә кую турында» Указына үзгәреш кертү хакында» 2015 елның 23 мартындагы ПУ-302 номерлы Указын.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 27 гыйнвар
№ ПУ-60

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның « 27 » гыйнварындагы
ПУ- 60 номерлы Указы белән
расланды

**Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын алучылар исемлеге**

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе.
2. «Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе.
3. «Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе.
4. «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе.
5. «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе.
6. «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе.
7. «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе.
8. «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе.
9. «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе.